Факил Сафин

Ләлә белән Арслан

«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ

Факил Сафин

Ләлә белән Арслан

БАЛАЛАР ӨЧЕН ХИКӘЯЛӘР, ӘКИЯТЛӘР

Казан
«Мәгариф» нәшрияты
2005

УДК 821.512.145-32-93
ББК 84(2Рос = Тат)-4
С 24

Рәссамы ***Валерий Булатов***

Сафин Ф. М.

С 24 Ләлә белән Арслан: Балалар өчен хикәяләр, әкиятләр /Факил Сафин.— Казан: Мәгариф, 2005.— 40 б.: рәс. б-н.
ISBN 5-7761-1476-4

ISBN 5-7761-1476-4

© «Мәгариф» нәшрияты, 2005
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2005

Кышның беренче көне

I

Әхәт иртән торып, тәрәзәгә күз салгач, тыштагы күренешкә исе китте. Әле кичә генә урамда яңгыр коя иде. Кичә генә түгел, озак көннәр яуды ул яңгыр. Инде туктый дисең, тагын сибәли башлый. Әхәтләр авылында балалар бакчасын, балалар аз дип, бөтенләй ябып куйдылар. Кая барасың, гел өйдә утырырга туры килә, көн бозылса. Менә шулай малай ай буе өйдә утырды. Бер-ике мәртәбә

манма булып чыланып, батып керде керүен, тик бер дә рәхәт түгел ул андый чакта. Әбисе дә орышып ташлый.

Әбисе, яңгырлы урамга карап, гел сөйләнеп йөрде.

– И-и көз озакка сузылды быел. Бәндәләргә сабырлык бир, Ходаем. Бу яңгырдан хайваннар да интегә торгандыр, агачларга да әйбәт түгелдер. Һәрнәрсәнең үз вакыты белән килүе яхшы. Яңгырга шәбәреп йөргән беркемгә дә җиңел түгел шу-ул.

Кичә дә Әхәт тәрәзә буеннан китмәде. Урамга карап торасы гына килә. Бөтен җирдә ялтырап торган күлдәвекләр, өй кырыенда үскән тирәктән өзелеп төшкән яфраклар әрле-бирле йөзәләр ул күлдәвекләрдә. Чып-чын көймәләр кебек чайкала алар, кечкенә дулкыннарга эләгеп. Ә һавада болытлар, болытлар. Үрелсә, Әхәтнең дә буе җитәр төсле. Авыр алар, Әхәтнең әнисе белән әбисе сарык йоны алганнар иде берчак, болытларны шул тузгып, күперәп, салынып-салынып торган йонга охшата ул. Менә шул болытлар урман артына таба салмак кына агалар да агалар. Кая да булса барып туктыйлар микән анда? «Карурман артына барып җыелалар да кире безнең авыл өстенә килеп, яңгыр булып явып китәләр алар»,– ди әтисе. Әтисе аның белми сөйләмәс.

Кичәге кебек түгел бүген көн.

Кыш килеп җиткән, ахрысы. Күлдәвекләрне көмештәй боз каплап алган. Әллә кояш та чыгарга исәпли – ара-тирә урам яктырып-балкып ала. Кояш болыт арасыннан җиргә бага, Әхәтне эзлидер шикелле инде менә.

Әхәт тиз генә ашады да әбисе китереп биргән киемнәренә тотынды. Өстенә җылы бишмәтен киеп алды, башына кызгылт бәйләм кәпәч менеп кунды, аякта – әтисе Чаллыдан алып кайткан шәп итекләр. Урамга ашкынып, йөгереп кенә чыкты. Салкынча, күңелле тышта. Озаграк йоклавына үкенеп тә куйды әле малай. Каяндыр кулына бер таяк килеп эләкте, капкадан урамга атылды, шома боз каплаган күлдәвектә шуа да башлады. Рәхәт инде, таягы белән бозга сугып та карады, кай арада шулай ныгыган бу боз, таяк белән сугуга исе дә китми, ватылырга уйламый да. Шу да шу. Ләлә белән Миләүшә чыкса, тагын да күңелле булыр иде, алар әле йокыдан яңа торып килә торганнардыр, кызлар бит алар иркәләнеп ятарга яраталар.

II

Әхәт исемле бер малайның шулай кыш җитүгә сөенеп, уйнап йөрүен Җил һич тә килештермәде. Ул ачуы килгәнен сиздерергә теләп, нык-нык итеп, Әхәткә кагылып-сугылып алды. Малай хәтта игътибар да итмәде Җилнең кыланмышына. Авызы ерык, күзеннән шатлык очкыннары сибелә, изүе ачыла төшкән – уйнавы уйнау һаман.

Җил тынычлана алмый тегендә-монда чапты, капкаларны шакып азапланды, электр чыбыкларына кагылып, аларны гүләтте. Аннан Суык абзыйсы янына чапты.

– Суык абзый, син тырышып-тырышып күлдәвекләрне боз белән каплап чыктың, мин сиңа булышып йөрдем, икәүләп кыш китердек җиргә, ә анда бер малай сине санга сукмый, хәтта мыскыл итәдер әле, бозга таяк белән китереп суга, ватмакчы була, өй яннарында шугалак ясап бетерде. Тапкан, имеш, уен...

– И Җилбану, пырдымсыз да инде син, – диде Суык абзый.– Җәй буе яныма килеп тә карамадың, хәзер шул малайга ачуың чыккан да минем янга йөгереп килдең. Бөтен балалар урамда инде бүген. Кышның беренче көне ич. Бик узынсалар, чеметтереп алырга була инде ул. Белсеннәр Суык абзаларының кем икәнен!..

Суык абзый, әләкче Җилне яратып бетермәсә дә, аның сүзен тыңлый иде. Үзен санга сукмаган җан ияләрен һәрчак үчекләп алырга ярата Суык абзый. Әхәт дигән малайны эзләп табуы да авыр булмады. Үткән кыш әле бик кечкенә иде, хәзер инде шактый үскән бу малай, дип тә уйлады әле. Чебен тигәнгә чер итеп йөрмәгәндер җәй көне. Артыннан бер тотам калмый ияреп йөргән Җилне бер капка төбендә калдырып, иркенләп тын алды Суык абзый, аннан, Әхәт ягына карап, сулышын өрә башлады: ыж-ыж-ж-ж... Малай, колаклары кызарып чыкса да, туңуны уйлап та карамады. Киеме уңайлы, җылы, үзе уйнап йөри, нигә өшесен ди ул! Ул гына да түгел, борын очына тир дә бәреп чыккан бугай әле. Иркенләп уйный бу малай, тиз генә бирешә торганнардан түгел.

Тагын бер мәртәбә сулышын өрде Суык абзый. Ыж-ыж-ж-ж... Инде Җил әйтеп тормаса да, Әхәт дигән малайны сынап карыйсы килә иде аның. Кесәсеннән алып, Әхәт кулына бияләй киде. Ярап куйды бит. Көн суытканнан-суыта, боз тагын да ныгыды. Шугалак та зурая, их, кайчан чыгарлар бу кызыйлар? Шундый көнне дә өйдә мыштырдап ят инде.

Ул арада ишеп-ишеп кар ява башлады. Моңарчы Суык бабай сүзен тыңлап, басылып торган Җилгә дә эш табылды – кар бөртекләрен бөтереп кенә ала да койма буйларына китереп сала. Үзе дә уенга һәвәс икән, тузгыта кар бөртекләрен, сибеп тә җибәрә, тирә-юньгә очыра, ә менә Кояшны каплап бетерә алмый. Кояш һаман җиргә карап-карап ала. Кар бөртекләре Әхәтнең башлыгына сарыла, керфекләренә килеп куна. Дөнья акка күмелә. И-и матур да соң бу кыш! Малайга бүген барысы да кызык тоелды. Ул йөгереп кенә өйләреннән бәләкәй чанасын алып чыкты. Бөтерелеп яуган карлар астында койма буендагы таулыктан чана шуа башлады. Бик үк ерак китеп булмый әлегә, чана кар астыннан кара җир эзләп табып төртелеп кала, тик бу инде өйдән тышка тилмереп карап тору түгел. Шәп, рәхәт!

Җил, тузынып арыгач, тагын Суык абзыйга әләкләшергә килде.

– Суык абзый, күр инде, теге малай мин өйгән кар тавын туздырып бетереп килә. Өенә куып керт әле шуны.

– Һем... Аларны куып кертеп өлгереп булырмы соң? Күрәсеңме, Әхәт янына чаналарын өстерәп ике кыз чыгып киләләр. Кыш үткәнче, без шул балалар иркендә инде, Җилбану. Йә, үпкәләмә, авызыңны турсайтырга гына торасың. Сүзең сүз булсын, тагын бераз суык җибәреп карыйм да...

Шул чагында болыт арасыннан Кояш килеп чыкты. Ул, сүрән генә яктыртса да, көнне балкытып җибәрде.

– Суыкбай, син инде Җилбануның сүзен тыңлап, сабыйларны өйгә куып кертергә тырышма, – диде ул. – Уйнасыннар! Шугалакларны, кар тауларын нигә ясыйсың соң син? Балалар уйнасын өчен түгелмени? Ничек көтеп алдылар алар ак карлы кыш килүен.

– Әлбәттә, балалар өчен ясадым кар тауларын, шугалакларны, – диде Суык абзый, кыланмышына оялган сыман.

– Шулай булгач, уйнасыннар сабыйлар. Таза, нык, чыдам булып үссеннәр, дөньяга ямь өстәп яшәсеннәр! – диде Кояш, күңеле булып.

Үлән урманы

Миләүшә, мөһим эше бар сыман, өй турыларындагы ком өемендә уенчык машинасы белән мәш килеп уйнап йөрүче Әхәт янына килеп басты. Әхәт күтәрелеп карамаска тырышты кызга, чөнки белә: Миләүшә ни дә булса уйлап чыгарырга оста, төрле сорау биреп аптыратып бетерә.

– Әхәт, беләсеңме, агачлар ничек зур булып үсә?

– Каян белим, – диде Әхәт, бу кызыйдан котылып булмасын аңлап. – Мин бит быел беренче сыйныфка гына керәм. Әбием әйтә, мәктәптә бөтенесенә өйрәтәләр, ди. Агачларның нигә зур булып үсүен дә өйрәтерләр.

– Урманның ничек үсүен дәме?

– Урманны да инде...

– Син мәктәпне көтеп яткан арада, мин инде боларны белдем, – диде Миләүшә, Әхәтне ирештергән кыяфәт белән. – Әтием әйтте.

– Әбием әйтә, бөтен нәрсә дә Ходай кулында, ди. Шулай булгач...

– Анысы дөрес, минем әнием дә шулай диде. Тик әйт әле, урман ничек урман була?

– Белмим дидем бит инде. – Әхәт читкәрәк китмәкче булган иде, кыз аның каршысына ук килеп басты.

– Ә син бел, уйла.

– Соң сиңа да әтиең генә әйткән ич. Белгәч, миңа да сөйлә.

Миләүшә аңлатырга теләп, бармакларын бөгә-бөгә тезеп китте.

– Башта орлык була. Кеп-кечкенә орлыклар. Дөге, карабодай ярмасы кебек... Күргәнең бармы?

– Булмыйча. Ботка пешерәләр ярмадан. Яратмыйм шул ботка ашауны. Өйдә ачуланып кына торалар шуның өчен.

– Мин дә яратмыйм шул, – диде Миләүшә, Әхәтнең хәленә кереп. – Ботка турында әйтмим лә мин, агачларның ничек үсүен сөйлисе идем.

– Сөйлә инде тизрәк, алайса. – Әхәт машинасы янына чүгәләде.

– Тыңла. Башта орлык була. Ул агачтан очып кына төшә дә коелган яфраклар астында күмелеп кала. Шунда кышны чыга. Аңа һич тә суык булмый икән, яфраклар каплап куйгач. Яз җиткәч, дымлы җирдә шытып чыга. Аннан кояш нурларында җылынып, яңгыр суларын эчеп үсә дә үсә, үсә дә үсә. Үсә торгач, зу-ур агач булып җитә. Күп агачлар үсеп җиткәч, урман була. Белдеңме инде?!

– Белдем, – диде Әхәт, артык исе китмәгән төстә. – Мин моны беләм, сиңа әйтмичә генә торган идем. Су сипкән саен, үсемлекләр шәбрәк үсәләр ул.

Миләүшә, бераз тын торгач, сер әйткәндәй пышылдый язып сөйләп китте.

– Әйдә, Әхәт, ишегалдында урман үстерәбез!

– Нинди урман?

– Ишегалдындагы үләннәргә су сибә башлыйбыз. Күп итеп. Көн саен, көн саен...

– Нигә? – дип, кызыксынып сорады Әхәт.

– Шушы Әхәтне... – диде Миләүшә, ачуланып.– Һич кенә дә аңламыйсың. Без су сипкән саен, үләннәр үсә торачак. Үсә-үсә алар зу-ур булырлар. Агачлар кебек. Үлән урманы үстерәбез дә тырыс алып кына йөреячәкбез шунда.

Әхәт тагын аңламый, сорау биреп ташлады.

– Нигә инде ул тырыс?

– Их, Әхәт, белмисең шул син! Урман читендә җиләкләр пешеп торыр, без шуны җыеп алырбыз да барысын да җиләк белән сыйларбыз. Кызыкмы?! Хәзер мин су сипкечне генә алып чыгам да... – Миләүшә, Әхәтнең җавабын да көтмичә, өйләренә йөгереп кереп китте.

Сыерчык

Айгөлнең әбисе авылда яши. Кызның иң бәхетле көне – Мәликә әбисе янына кунакка кайткан көне. Дөньяда аннан да ягымлы, якты йөзле, нурлы карашлы әби башка юктыр. Дүрт яшьлек Айгөл, моны үз теле белән әйтеп бирә алмаса да, шулай булуын әйбәт төшенә иде.

Менә бүген дә әтисе, әнисе, кеп-кечкенә энесе Рөстәм белән әбиләренә кунакка кайтып төштеләр алар. И сөенде Мәликә әбисе, кунаклар кайткач, очып кына йөри инде. Айгөл белән Рөстәмне бигрәкләр дә ярата ул.

Чәй эчеп алгач, Айгөл ишегалдына чыкты. Үткән кайтканда, әтисе матур итеп сыерчык оясы ясап куйган иде. Ояга сыерчыклар килгән икән. Моңа әтисе куанып бетә алмый. Кызын кулына күтәреп, оя түбәсенә кунган сыерчык сайравын тыңлады алар. Әтисе Айгөлгә аңлатып бирде.

– Бусы – әти сыерчык, – диде ул, – әни сыерчык исә ояда. Йомыркалар салган да хәзер бәләкәй сыерчыклар тишелеп чыгуын көтеп утыра. Әти сыерчык, әрсез мәче оя тирәсендә йөрмәсен дип, аларны саклап тора. Сайравы: «Борчылма, әнкәсе, мин гел шушында, сезне саклап кына торам», – дигәнне аңлата.

– Әнә бит хәзер очып китте.

– Ул бит – акыллы кош. Минем оя ясап биргәнне белә, без сыерчыкларга начарлык эшләмәсен дә белә. Җим эзләп очты ул. Аларга да ашарга кирәк ич. Без бар чакта, мәче ояга якын килергә курка. Шуңа күрә саклап торыйк әле, сыерчык иркенләп очып кайтсын.

Әмма әти сыерчык озак тормады. Томшыгында нәрсәдер бар иде.

– Менә нинди әйбәт сыерчык бу, – диде әтисе, сокланып. – Үзенә дә җим тапкан, әнкә сыерчыкка да алып кайткан. Ничек тату, матур яши бу кошкайлар!

Яннарына Мәликә әбинең килеп басканын сизмәгән дә иде Айгөл. Әбисе, әтисенең аркасыннан сөеп:

– Рәхмәт, кияү, ишегалдына нур керде шушы сыерчыклар белән. Күңелем булганчы карап торам мин аларны, үземнең яшь вакытларны, бабаң исән чакларны искә төшерәм. Ул да бик тынгысыз, гаилә җанлы кеше иде, мәрхүм. Үзенә булмаса булмас иде, балалар өчен җанын да бирергә әзер иде. Сез киткәч, гел шушы сыерчыклар

белән сөйләшеп, серләшеп йөрим мин. Кошкайларны сөендергән өчен, Ходай юлыңда гел әйбәт кешеләрне генә очратып торсын... – Әбисе алъяпкыч очы белән күз яшен сөртеп алды.

Әтисен мактауны ишетү Айгөлгә бик рәхәт иде.



Очрашу

Айгөл бүген әтисе белән урамга чыкты. Көн кояшлы, ямьле. Өй турыларыннан бераз киткәч, ямь-яшел болын башлана. Тагын бераз баргач, зәп-зәңгәр күл. Айгөлне әтисе кулыннан җитәкләп кенә йөри. Йөгереп китеп, берәр ташка абынып егылыр, кулын, тезен авырттырыр дип курка инде ул. Монда бит яңа йортлар төзиләр. Машиналар үтеп-сүтеп кенә тора. Айгөлнең шул машиналарга утырасы килә, әтисен алар йөри торган якка әйдәли. Кечкенә шул әле ул, машиналар юлына чыгарга ярамаганын аңламый.

Әтисе кызын җитәкләп, болынга таба алып китте. Үзе сөйләнеп бара:

– Айгөл кызым үсеп җиткәнче сакланса бик әйбәт булыр иде дә бу болын, сакланмас шул. Йортларны төзиләр дә төзиләр әнә. Шәһәр үсә дә үсә. Шәһәр үскән саен, без кечерәябез кебек.

Айгөл болынга чыккач иркенәеп китте. Әтисе дә инде кулын җибәрде. Кыз бер сары чәчкә янына чүгәләп утырды. Кояш астында балкып утыра бу чәчәк. Үзенең бихисап күп керфекләре. Һәркайсыннан сары яктылык бөркелә. Әйтерсең күктән кояш төшкән болынга. Чәчәк таҗына бер бал корты килеп кунды. Нәрсәдер эзли ул, сары керфекләрне үбеп-үбеп ала, туктаусыз йөренә, туктаусыз нидер сөйләнә.

– Тузганак чәчәге бу, кызым. Менә шулай балкып утыра да тагын берничә көннән ап-ак шарга әйләнә ул. Җил искән саен, шул ак шарның бөртекләре җир буйлап сәяхәткә китә. Кайда барып төшсә, шунда үсеп чыга, тагын менә шундый чәчәкләр балкый ул төштә. Кемдер чүп үләне ди, кемдер дару үләне ди, аңламассың бу дөньяны.

Әтисе шулай кызык сөйләшә инде Айгөл белән. Олыларча итеп, җитди итеп.

Айгөл бал кортына үрелде. Әтисе иплəп кенә кызының нәни кулын читкә этәрде.

– Бал корты чәчәккә кунган. Бал җыя ул шулай. Айгөл авырмасын, салкын җил кагылып китеп йөткерә башласа, минем балымнан авыз итсен, тиз генә терелеп тә куяр, ди. Кагылсаң ачулана, кулыңны чагып та алырга күп сорамый. Эштән аерасыз мине, ди.

Бал кортының шулай Айгөл өчен тырышып-тырышып бал җыюын белгәч, бигрәк тә сөенде инде кыз үзе.

Күрми дә тора икән, алар яныннан бер апа үтеп бара. Апаларны күп күргәне бар Айгөлнең, бу апа бер кечкенә көчек җитәкләгән, сокланып карап туймассың. Барып кочаклыйсы, шул көчек белән уйныйсы, болын буйлап чабасы, куышасы килә.

Әтисе, Айгөлнең ни уйлаганын сизгән кебек, тиз генә аның кулыннан җитәкләп тотты.

Теге көчек тә Айгөлне күреп алды. Апасы янында теркелдәп барган көчек шып туктап, кәкрәйгән койрыгын өскә күтәреп, әле бер якка, әле икенче якка җилпеп тора әнә. Ак төстәге көчек бик матур иде, салынып төшкән колаклары кара тимгелле аның, аяклары йөнтәс, юантык, үзе Айгөлнең курчагыннан чак кына зуррак булыр. Кызның көчекне кулына күтәреп аласы килде. Аңа тартыла, тик әтисе кулыннан нык эләктергән шул, җибәрми генә. Көчек зур күзләрен мөлдерәтеп, Айгөлгә карап тик тора. Карасу дымсу иреннәре кыймылдап алды. Айгөлне үзе янына чакыра ул:

– Ник шулай карап торасың инде? Кил минем яныма, кечкенә кызый. Икәүләп уйныйк шушы болында. Әнә күпме иптәш монда безгә уйнау өчен. – Ул баш очыннан канат җилпеп үткән күбәләкне күреп, урынында әйләнеп алды да янә Айгөлгә текәлеп тора башлады. Сөйләшәсе килә инде аның Айгөл белән.

Айгөл әтисенә карап, бармагы белән көчек ягына ишарәләде. Бәләкәй шул әле ул, менә шулай бармак төртеп кенә аңлата.

– Әтием, миңа да шушындый матур көчек алып бир, – ди инде ул. – Менә шундый акыллы көчек, минем белән сөйләшә, мине ярата торган көчек. Ә хәзер аның белән уйныйсым килә, мин аны бик яратам. Ул да мине ярата, күрәсеңме, үз янына чакырып тора.

Көчекнең апасы каядыр ашыга иде шул. Озаклап сөйләшеп булмады. Чөнки кызны әтисе җитәкләгән, көчекне апасы бәйдә тота, һәркайсы үз юлын карый. Көчек әле бик озак Айгөл ягына карап-карап барды. «Нинди матур көн иде, нинди акыллы кыз очраган иде, бергәләп уйнарга да рөхсәт итмәделәр бит», – ди торгандыр инде ул, әйеме?..



Дуслык

Очкыч макеты ясап утырган Әхәт янына, сулышы кабынырдай булып, Азат килеп керде. Күзләрен хәйләкәр кысып, авыз чите белән бер көлемсерәп алды да, сәлам дә биреп тормастан, сүз башлады.

– Бөтен сыйныф белән беренчеләр янында кайнашабыз, ә синең уеңда да юк. Бүлмәдән чыгып та карамыйсың.

– Ярышка әзерләнәм бит, макетчылар ярышы үтә шәһәрдә. Мәктәпнең данын якларга җыенабыз.

– Кем сине анда йөртсен инде, бишенче сыйныфта укыганнарны анда алып та бармый торганнардыр әле.

– Карарбыз инде. Мәктәптә кем беренче урынны ала, шул шәһәркүләм ярышта катнаша. Анда урын алсам...

– Ниятләрең зурдан икән. – Азат көтмәгәндә ягымлы тавыш белән сөйләшүгә күчте. – Кара әле, Әхәт, син бик матур итеп рәсем ясыйсың бит, бер ярдәм күрсәт әле беренче сыйныфтагыларга.

– Нинди рәсем? Әле беркөнне генә зур кәгазьгә мәкальләр яздырып алган идең. Шул беренчеләр дип, макетны вакытында өлгертә алмыйча яна яздым.

– Йә инде, дуслык хакы – Тәңре хакы, ди безнең әби. Ул чакта ике командага бүленеп ярышкан идек, безнең команда беренче урынны алды. Музейга экскурсиягә алып бардылар. Мин дә бардым. Синең матур итеп язган мәкальләрең булмаса, күпме бала мәхрүм кала иде экскурсиядән. Бу юлы табигатьне саклау темасы буенча ярыш. Циркка бара беренче урынны алучылар.

– Соң гел сиңа гына кушалармыни рәсем ясауны?

– Йә инде, кыланма, башка эшкә осталык юк. Шефлыкка алдым ич беренчеләрне. Аларга шеф булучыларның тәртибенә «биш» чыгарам диде бит сыйныф җитәкчесе, риза булдым инде. Алтынчы сыйныфка күчкәч, махсус мәктәпкә барырга җыенам, анда тәртип билгесенә нык карыйлар, ди. Аннан циркка да барасы килә.

– Өлгереп кенә булмый, Азат, үземнең дә эшем күп. Үзең тырышып кара инде, бөтенләй үк булдыксыз малай түгел ич син.

Азатның күзләре яшьләнгән сыман булды.

– Минем дә вакыт юк, Әхәт. Инша язылып бетмәгән әдәбияттан. Шул беренчеләр ди торгач, уку гел артка тәгәрәде.

Азатның, беренчеләргә ияреп, йә экскурсиягә, йә кинога йөрүдән бушамаганын белсә дә, Әхәт аның белән сүз көрәштереп тормады.

– Ниндирәк темаларга ясыйм соң ул рәсемнәрне? Әйтеп, күрсәтеп бир, ичмасам. Гомуми теманы әйттең дә шул җитте дип уйлыйсың, ахры.

– Тот та яса инде, син барыбер мин өйрәткәнне яратмассың. Үзең әйтмешли, башсыз малай түгел лә син! Дуслык хакына...

Әхәт ул көнне, үз эшен ташлап, рәсемнәр ясады. Аннан соң гына макетына тотынды. Эшен тәмамлаганда, ярты төн җитеп килә иде.

Икенче көнне дәресләр бетүгә, Азат ул рәсемнәрне алып та китте. Рәхмәт әйтергә дә онытты бугай, оча гына. Дустының сөенечен күреп, Әхәт тә күңелендә җиңеллек тойды. Ярдәм итми калса, күңелсез булыр иде аңа.

Ул, шулай уйлана-уйлана, өенә кайтырга кузгалды. Озын коридордан үткәндә, ирексездән беренчеләр укый торган сыйныф бүлмәсе янында тукталды. Бүлмә ишеге ачык, укытучы апаларының тавышы аермачык ишетелә.

– Менә, балалар, безнең сыйныф тагын беренче урынны алды бу ярышта. Монда да безнең шефыбыз Азатның ярдәме зур булды. Теге чактагы кебек, бу юлы да аның рәссам осталыгы җиңүгә хәлиткеч өлеш кертте. Аңа рәхмәтебез чиксез, инде бергәләп циркка барып кайтырбыз, шулай бит! Бу кадәр оста итеп рәсем ясарга каян өйрәндең, Азат?

Азат урыныннан торып, сүз башлады.

– Осталыкның нигезендә тырышлык инде, Нурия Хәлимовна. Башта озаклап темаларны уйлап йөрдем, аннан, төне буе дисәң дә ярый, рәсем ясадым. Бер малайга булыш дигән идем, кая ул, вакытым юк дип, кулын гына селтәде. Уйнаганда гына дуслар күп була ул, эшкә дисәң, юк...



Ләлә белән Арслан

Ләлә, урамга чыгуга, каршы як капкасы төбендә басып торган ят малайны күреп алды. Башына килгән беренче уе: кем бу? соравы булса, икенчесе тизрәк өенә кире кереп китү иде. Яратып бетерми малай-шалайны Ләлә. Үзләре сугышалар, үзләре әләкләшәләр. Шулай да кызыксынуы җиңде, калды капка төбендә. Мәликә әбиләргә кайткан кунак малаедыр инде. Аларга шәһәрдән еш кайта кунаклар. Тик бу малайны беренче күрүе Ләләнең. Кыз белә инде: шәһәр малайлары кылтык була алар. Үзләре, җигүле ат күрсәләр, арбасына ничек менәргә белмичә аптырап калалар, арба артына тотынып та бара алмыйлар әле, үзләре мактанырга яраталар. Имеш, шәһәрдә ваннада гына йөзеп яталар. Имеш, анда зоопаркка йөриләр. Зоопаркта ни бар дигәч, әтәчләр күрдек, бәләкәй атлар, диләр. Ләлә көлеп үлә язды. «Монда көн саен зоопарк, – ди әтисе. – Ишегалдына чыксаң, барысы да бар: сыер, сарык, кәҗә, әнә уйнаклап колын чабып йөри әнкәсе янында. Тагын каз, үрдәк, тавык...» Бу малайның да шулай мактанып, тәкәбберләнеп сөйләнүен ишетәсе килеп тормый әле! Ләлә кереп китәргә җыенып беткән иде инде, капкадан Мәликә әби килеп чыкты. Кулында талчыбыктан үргән тирән кәрзин. Кәрзин эчендә каз бәбкәләренең пип-пи-пип килүе ишетелә. Бәбкәләр беренче мәртәбә шулай зур сәфәргә чыгуларына куанышалар, ду киләләр. Мондый кызык тамашаны ничек ташлап кереп китәсең? Ләлә, дөньясын онытып, Мәликә әбинең һәр хәрәкәтен, һәр адымын күзәтә башлады. Теге малай шундук хәтердән чыкты. Малай-шалай кайгысымы мондый чакта!

Мәликә әби, урам почмагындагы матур чирәмлеккә җиткәч, кәрзинен сак кына яшел үлән өстенә куйды. Бисмилласын әйтеп, кәрзиннән сары йомшак бәбкәләрне, берәмтекләп алып, күпереп үскән чирәм өстенә җибәрә башлады. Җиргә аяк басуга, бәбкәләр ни генә кыланмыйлар! Нәни канатларын җилпи-җилпи очарга маташалармы шунда. И очыналар, и очыналар, үзләре аякларында да ныклап тора алмыйлар югыйсә. Артларына чүгеп-чүгеп куялар, бер-берсенә нечкә муеннарын сузып нидер әйтәләр, сөйләнәләр, пипелдиләр, бер-берсен тыңлап та карамыйлар – һәркайсы үзенекен пипелди. Исләренә килеп, нәни томшыклары белән сусыл яшел үлән чемчекләргә азапланалар, үләнне өзә алмыйча тарткалыйлар, артларына егылып китәләр. Үзләре һаман сөйләнгән булалар. Ул



арада каң-гак килеп капкадан ана каз белән ата каз килеп чыкты. Аларны моңарчы чыгармый торганнардыр инде.

Ләлә, үзе дә сизмәстән, каршы якка, бәбкәләр янына чыгып бара икән, казларны күргәч, урам уртасында шып басып калды. Курка ул ата каздан.

Ана каз бернәрсәгә күз салмый, нечкә муенын алга сузып, вак, җитез адымнар белән бәбкәләре янына ашыкты. Ата каз исә бер урында тыпыр-тыпыр әйләнеп алды. Олы канатларын җилпеп, урамны күзәтеп алгандай итте, күзе урам уртасында басып торган Ләләгә төште, шул гына кирәк дигәндәй, кыйгак-кыйгак кычкырып, кызга таба йөгерә башлады.

Ләләнең аяклары җиргә берегеп калдымыни?! Кымшана алмый тик тора. Ичмасам, Мәликә әби дә карамый бу якка, бәбкәләр белән әвәрә килә. Кычкырып елап җибәрсә инде... Томырылып килгән ата каз бик тиз якынлаша шул аңа. Кызның күзеннән яшь атылып чыкты, ул озын керфекләрен түбән төшерде, елап җибәрергә әзерләнеп, кечкенә иреннәрен бөрештереп куйды.

Инде елап җибәрәм дигәндә, кискен тавыш ишетелде:

– Кая барасың, явыз! Көш-көш, синең бәбкәләрең монда түгел, әнә әби янына йөгер!

Кыз күзләрен ачты. Кай арада теге малай ата казның юлына каршы төшеп өлгергән диген. Кулында Мәликә әбинең тилгән-карга куарга дип әзерләгән шыштырдавык бәйләнгән таягы. Малай, куркуның ни икәнен дә белмәгән сыман, таягын җилләнеп селки-селки, ата казны читкә куып алып китте. Ата каз бик тә зур эш башкарган кыяфәттә ана каз янына ук килеп каңгак килеп каңгылдый, нидер аңлата башлады. Мактанчык икәне әллә каян күренеп тора үзенең. «Ярый әле күреп калдым. Бер кызый бәбкәләрне алып китмәкче иде, пыр туздырып, куып җибәрдем. Әгәр теге җүнсез малай юлыма каршы төшмәсә, аягын чукып алырга да күп сорамас идем...» – ди торгандыр инде. Ата каз чыннан да шулай дисә, алдакчы икән! Алдашу ярыймы соң инде? Ләләнең бәбкәләргә якыннан гына карап торасы килгән иде бит.

Ул арада кунак малай Ләлә янына ук килеп басты.

– Курыктыңмы! – дип сорады ул ачык тавыш белән, ак тешләрен күрсәтеп елмаеп та куйды. Күрдеңме, ата казны мин ничек куып җибәрдем, дип мактана башлый инде хәзер. Мактану һич тә килешми. Моны әтисе гел әйтә аңа. Мактанчык, кылтык кешедән рәт чыкмый, ди. Рәт дигәнен белеп бетерми Ләлә, әмма андый

кешеләрнең әйбәт үк булмау ихтималын чамалый. Әтисенең иң сөймәгәне исә – алдашу. Ләлә дә шундый начар сыйфатларны яратмый. Малайга җавап кайтармый булмый.

– Курык...тым шул. – «Курыкмадым» дия язды тагын, оялып күзләрен читкә алды.

– Мин булганда, син курыкма!

Һи, мактанчык ич бу!

Малай сөйләнүен белә.

– Синең исемең ничек? Минеке – Арслан.

Аның исемен сораган кеше дә юк әле монда. Шулай да кыз җавап кайтарды:

– Ләлә – минем исемем.

– Ләлә?.. Ә ни дигән сүз ул?!

Ләлә аптырап калды.

– Ничек инде? Минем исемем Ләлә! Менә шул.

– Исем болай гына булмый ул. Ышанмасаң, әнидән сорыйбыз. Минем исемем Арслан. Кыю, җитез, көчсезләрне яклаучы дигән сүз. Синең арыслан дигән җанварны күргәнең бармы?

Телевизордан күп тапкырлар күрде Ләлә арыслан дигән җанварны. Аңа хәтта куркыныч булып китте. Ул арыслан дигән җанвар бер бәләкәй генә болан баласын эләктереп, сыртына салып элдертте. Кызның күзләрендә курку күреп, Арслан тагын елмайды.

– Курыкма, Ләлә, мин бит башкаларны яклый торган Арслан. Әбием әйтә, син әйбәт бала булып үссен өчен, шундый исем куштык, ди. Мин көчсезләрне һәрчак яклыйм. Бакчада кызларны берәр малай елата башласа, шундук ул малайны бөтереп салам.

– Әтием, сугышу әйбәт эш түгел, ди. Мактанма!

Арслан аптырап калды.

– Мин бит сугышмыйм, яклыйм гына! – диде ул, күзләрен зур ачып. – Менә бүген сине яклаган кебек... Егет кеше мактанмый ул. Әбием гел әйтә моны миңа.

Ләләгә Арсланның сүзләре ошады.

Малай исә кыю, һаман сорашуын белә.

– Шулай да әйт инде, Ләлә ни дигән сүз?

Менә бәла: Ләлә үзенең исеменең нинди сүз булуын әллә гел белми, әллә ата каз белән булган вакыйгадан соң онытып җибәрде, ул кырт кына өйләренә таба борылды.

– Кая киттең, Ләлә? – диде Арслан, күңелсезләнеп.

– Исемемнең нинди сүз икәнен белмим бит. Өйгә кереп, әнидән сорап чыгам.

– Мин дә керимме?

– Әйдә, алайса...

Ләләнең әнисе ишегалдында юылган керләр элеп йөри иде. Ләлә аның янына йөгерде, килгән уңайга:

– Әнием, Ләлә нинди сүз була ул? – дип сорады.

Әнисе, аптырап, бер кызына, бер таныш түгел малайга күз ташлады, көлемсерәп җавап бирде:

– Ләлә синең исемең ич инде. Бик матур сүз ул.

Ләләне бу җавап канәгатьләндермәде.

– Менә бу малайның исеме Арслан. Мәликә әбиләргә кунакка кайткан ул. Кыю, көчле, кызларны яклаучы икән Арслан дигән исем. Ләлә ни дигән сүз, дип сорый миннән...

– Ә-ә, аны әйтәсең икән, кызым. Хәзерге балалар... белмәгәннәре юк... – дип көлеп җибәрде әнисе. – Синең исемеңне ләлә чәчәге исеменнән алдык. Яз көне, ләлә чәчәк аткан чакта туган идең. Әтиең сине, алтынсу чәчләреңнән сыйпап, сары ләләм дип кенә йөртә. Сары ләлә – муллык, уңганлык, матурлык билгесе.

Ләләнең йөзенә елмаю җәелде.

– Белдеңме инде минем исемне? – диде ул Арсланга. – Матур бит!

Мактана төшүен сизеп, керфекләрен түбән төшерде. Битенә кызыллык йөгерде.

Арслан да шат. Ләләнең исеме дә, үзе дә аңа бик ошый иде.



Рәхәт көн

Тып-тып... Тып...тып...

Каен кызы йокыдан уянды. Тирә-якка күз ташлады.

Һәрьякта ап-ак кар иде. Тыныч йокысыннан кем уятты аны? Беркем күренми. Шулай да бүген көн үзгә кебек. Кәүсәсе, ботаклары буйлап рәхәт җылылык тарала. Каен кызы югарыга караган иде, сөенеп, җил көенә чайкалып куйды. Өстә, бик биектә зәп-зәңгәр һава диңгезе, нәкъ баш очында кояш яна. Рәхәт, кояшлы, бик күңелле көн иде бу. Каен кызы янә күзләрен йомды. Әмма бая ишетелгән тавыш тагын кабатланды. Тып-тып... Ул гаҗәпләнеп күзләрен ачты. Теге тавышның иясен һич кенә дә таба алмый. Тып-тып, тып-тып... Тавыш кабатланган саен, кәүсәләрнең ныграк җылынуын тоя барды Каен кызы. Әнә яшь-яшь ботаклардагы нәни бөреләр дә нидер пышылдашалар, керфекләрен чак кына тибрәлдереп, кояшка карыйлар. Бөреләр дә уяна бу серле тавышка. Тып-тып, тып-тып-тып... Нинди тавыш бу?

Шулчак аның ботагына бер чыпчык килеп кунды. И канатларын кагына, и чыркылдый соры чыпчык. Чык-чырык, чык-чырык... Тып-тып-тып, тып-тып-тып... Чык-чырык, чык-чырык... Тып-тып, тып-тып-тып... Каен кызы озак, тыныч кыштан соң беренче мәртәбә шундый җанлылыкны күрә. Тынычлыгы югалса да, ачуланасы һич тә килми. Кояш, зәңгәр күк, ара-тирә исеп куйган дымсу җил, чыпчыкның шулай шатланып чыркылдавы аңа ошый иде.

Менә тагын бер чыпчык килеп кунды. Урман ешлыгыннан килде, ахры. Тегесе сорырак иде, бусы ачыграк төстә, бүз түшле, койрыклары да озынча, үзе бик сөйкемле. Инде икәүләп чыркылдый алар. Чык-чырык-чык... Чык-чырык. Каен кызына чыпчыклар таныш иде, үткән ел да алар, очып, уйнап арыгач, аның куе яфраклы ботакларына кунып ял итә иделәр. Аларның берсе – Сорыкай, икенчесе Аксыл исемле. Әнә бит сүзләре дә аңлашыла.

– Кара әле, Сорыкай, Каен кызы ник елый ул?

– Еламый ич, Аксылым. Әнә ботакларына кара син. Нинди матур алкалар аскан алар. Шул алкалардан тамчы тама. Ишетәсеңме: тып-тып, тып-тып...

– Һи, Сорыкай, алка түгел ич алар. Кыш бабай Каен кызының ботакларына боз сөңгеләр элеп куйган иде. Яңа ел бәйрәмендә. Хәтерлисеңме?



– Истә, Аксылым, бик салкын көн иде ул. И салкын, карлы булды быел кыш.

– Кыш шулай була инде ул. Кары күп булгач, җәйгә яхшы: чәчәкләр күпләп үсәр, басуларда арыш-бодай уңар. Һәркайсы орлык бирер, безнең тамак тук булыр.

– Акыллы да инде син, Аксылым, сине тыңлавы рәхәт.

– Шулай да әйт инде, Сорыкай, Каен кызы ник елый?

– Еламый ич.

– Тыңла, алайса, ишетәсеңме! Тып-тып-тып... Тып-тып-тып...

Каен кызы бу сүзләрне бик кызыксынып тыңлады. Сорыкайның җавабын аның да ишетәсе килә.

– Әйтәм ич, еламый ул. Кыш бабай тагып киткән боз сөңгеләр кояш нурлары белән шаярып-уйнап алмакчылар иде, эри башладылар. Кояшның үз эше, ул җиргә яз алып килә, ә бозлар эри дә эри. Тып-тып итеп тамчылар тама. Их, нинди матур бу көн! Аксылым, димәк, Каен кызы да шатлана торгандыр инде, яз җитүен белгәч.

– Яз килүенә барыбыз да сөенәбез, Сорыкай.

Тагын җил исеп куйды. Тамчылар тама да тама. Каен кызы, Аксылның сүзләрен ишеткәч, сөенеп, кояшка карады. Ботаклары шаулаштылар. Аның якты кояшка рәхмәт әйтүе иде бу.

Тып-тып... тып-тып-тып... Тамчылар тамуын тыңлап, кояш астында җылынып утыруы бик тә рәхәт иде Каен кызына.

Кызык итте...

Соңгы вакытта Айгөлне ишегалдына бик чыгармаска тырышалар. Әле әтәч талый диләр, әле ата каз дип куркыталар. Чебиләр, каз бибиләре анда, Айгөлнең бик тә күрәсе, аларны кулына тотып карыйсы, алар белән уйныйсы килә. Ә чыгармагач, аксыл йомгак чебиләрне дә, сары йомшак бибиләрне дә кулга алып булмый инде ул.

Бүген аңа уйнап керергә рөхсәт иттеләр. Әнисе өй җыештыра, Айгөлнең җиң сызганып чиләккә таба килүен күргәч, аны уйнап керергә чыгарып җибәрде.

Койма буендагы челтәр тәрәзле читлектә чебиләр ярма бөртекләре чемченеп йөргән булалар. Аларны читлектән бик чыгарыр иде Айгөл, ишек келәсенә буе җитми. Ярый, челтәр тәрәздән карап торсаң да кызык икән.

Ул арада бакча артыннан кайтып килүче Мәликә әбисе күренде. Алъяпкыч итәген кайтарып тоткан. Айгөлнең күргәне бар: әбисе чебиләргә үлән йолкып алып кайта шулай. Алып кайткан үләнне ләгәнгә салды да, Айгөлгә һичнигә кагылмаска кушып, нәрсәдер алып чыгарга өйгә кереп китте әби. Айгөлгә шул гына кирәк тә. Ничек инде кулга тотып карамый түзәсең үләннәрне. Кызыктыра бит.

Мондый эре, тере яфраклы үләнне бер дә күргәне юк иде Айгөлнең. Сокланудан йөзенә яктылык җәелде. Тиз генә барып, бер бәйләм үләнне кулына алган иде, нәни бармакларын кайнар су пешекләп алдымыни! Яндыра, әчеттерә. Айгөл чыр итеп кычкырып елап җибәрде.

Ишектән берьюлы диярлек әнисе белән әбисе йөгереп килеп чыктылар.

– Ни булды тагын? – диде әнисе, куркынган тавыш белән.

– Әтәч явыз кетәклектән чыкмагандыр бит? – диде әбисе. – Югыйсә ныклап ябып куйган идем...

Айгөл әрнегән кулын өскә күтәрде.

– Ай-ай... – дип такмаклады ул. – Авырта-а...

– Кычыткан бәласе икән бу, – диде әбисе, хәлгә төшенеп. – Әйттем, бернәрсәгә дә кагылма, дидем...

– Кычытмый, авырта-а, – дип үксүен белде Айгөл.

– Кычыткан... – Әбисе сүзен әйтеп бетермәде, Айгөл тагын да ныграк үкси башлады:

– Кычытмый, авырта-а...

– Аңладым, аңладым, – диде әбисе, көлемсерәп. «Өф-өф» итеп, кызчыкның бармагына өреп алган иде, бармакның әрнеп сулкылдавы басыла төште.

– Менә бу тешләде... – диде Айгөл, әбисенә сыенган килеш, эре яфраклы үләнгә ачулы карап.

– Бу үлән кычыткан дип атала да инде, кызым. Тешләми ул, чага. Мин яшь кычытканнарны бакча артыннан алып кайтам да чебиләргә турап бирәм. Яраталар аны наныйлар. Кычытканны ашагач, алар авырмый, тиз үсәләр. Менә шундый бик файдалы үсемлек булгач, аны өзеп алучылар да күп була. Ул үзенә кагылган кешеләрне куркытам дип чагып ала.

Әбисе файдалы дип бик мактаса да, Айгөл кычытканга яңадан кагылмаска булды. Үсә бирсен койма буенда. Әбисе белән дуслашканнардыр алар, аны бер дә чакмыйлар ич.

Фазыл чишмәсе

Фазыл, әтисенә ияреп, басу артындагы печәнлеккә барган иде. Көн эссе. Әтисе тирләп-янып печән чаба, Фазыл әтисе артыннан таралып калган учмаларны җыйнап, тиземгә сала. Арыса, куак астына корылган кечкенә куышта ял итеп ала. Әмма ял итәргә җай юк. Аз гына хәрәкәтсез торсаң, тирә-ягыңны кигәвен, черки сарып ала. Алар бу болында шулкадәр күп, әйтерсең дөньядагы бөтен кигәвен, бөҗәк халкы шушында килеп тулган да, Фазылның алардан котылырга теләвен күреп, рәхәт чикмәкче.

Бераздан Фазылга чынлап эш табылды. Әтисе аңа кичә чапкан тиземнәрне әйләндерә барырга кушты.

– Болай булса кичкә без аларны күбәгә дә куя башларбыз, – диде ул, канәгать тавыш белән. – Кырда үскән тукранбаш түгел инде болын печәне. Бозауларга, кечкенә бәрәннәргә менә шушы уйсу болында күпереп үскән йомшак печән әйбәт була, – дип тә өстәде.

Әбәт вакыты җиткәндә, кояш тагын да кыздыра башлады. Чыдап кына булмый. Әтисенең ял итеп алыйк булмаса дигән сүзләрен ишеткәч, Фазыл тырмасын куыш янына сөяп куйды да, кулына көрәк алып, Тирән чокыр ягына атлады.

– Кая барасың? – дип аптырап сорады әтисе. – Ял итеп ал бераз. Әле эш җитәрлек монда, юкка көч түгеп йөрмә.

– Кичә Тирән чокырның уртасыннан су тибеп чыккан төшне күргән идем. Шуны чистартып карыйм.

Тирән чокыр дигәне Фазыллар кышын чаңгы шуып, җәен җиләк җыеп йөри торган тау асты инде аның.

Әтисе печән өстенә таралып ятмакчы иде, Фазылның сүзләрен ишеткәч, урыныннан кузгалды.

– Гаҗәп, без малай чакта анда чыннан да бер чишмә бар иде, – диде ул. – Аннан эзен алыштырдымы, әллә яр ишелде, юкка чыкты. Бәлки син шул чишмәгә тап булгансыңдыр. Тәмле сулы, шифалы чишмә ул. – Кызыксынуы көчле булгандыр инде, әтисе дә, Фазылга ияреп, Тирән чокырга таба атлады.

Әтисенең сүзләреннән Фазыл бигрәк тә канатланып китте.Тирән чокырга килеп җиткәч, иске сукмакка тап булдылар. Аны үлән, ат



кузгалагы, әрекмән басып китсә дә, монда кайчандыр сукмак булганлыгы әйбәт төсмерләнә иде.

– Йә, Хода, нәкъ шул чишмә сукмагы ич бу, – диде әтисе, сөенечен яшермичә. – Безнең бабайлар, әткәйләр, суын эчеп, сусавын баскан чишмә. Мин аны эзләп карадым, һич кенә дә таба алмадым. Менә кайда яшеренеп яткан икән ул.

Тауның яртысына төшеп җиткәч, Фазыл бераз читкәрәк каерды. Ак ташлы тау битенең өстәл кадәр җире кисәк уелып аска төшә, ул урын исә катлам-катлам таш кына, ташлар чилләдә янып эшләгән кешенеке төсле тирләп чыккан дисәң дә була. Төрле җиреннән шыбыр-шыбыр су бәреп чыгып, үләннәр арасына кереп югала.

– Шушы чишмә инде ул, – диде әтисе, кулы белән тирләгән ташларны сыйпап. – Тик урыны гына бүтән. Күрәсең, ярлар ишелеп, эзен югалтып торган да яңадан җир өстенә бәреп чыккан. Аллага тапшырып, сак кына таш араларыннан юл яса әле, улым, чишмәсенә үк тап булмассыңмы!

Әтисенең сүзе дөрескә чыкты. Фазыл тирләп-пешеп бераз маташкач, җир өстенә челтерәп чишмә бәрде. Башта, ник минем тынычлыгымны боздыгыз дигән шикелле, иренеп, болганчыкланып акты ул, ә бераздан, иреккә чыгуына сөенеп туя алмыйча, тау бите буйлап түбәнгә челтер-челтер көмештәй акты су йөгерде.

Әтисенең дә куанычы эченә сыймый. Нидер уйлап, куаклар арасына кереп китте, аннан, каяндыр табып, җыйнак кына кабык колаша алып чыкты һәм чишмә юлына әйбәтләп урнаштырып куйды. Инде чишмәнең тавышы әллә кайдан ишетелеп торырлык булды.

– Әйбәт тибешле чишмә бу! – диде әтисе. – Үзең тапкан чишмәнең инде суын да эчеп кара. – Ул әрекмән яфрагын җай гына бөтәрләп алган иде, җыйнак, ипле савыт килде дә чыкты.

Чишмәнең суы тешләрне камаштырырлык салкын, искиткеч тәмле иде.

Бу вакыйгадан соң байтак вакыт үтте, Фазыл үсеп җитте, ә аның чишмәсе һаман челтерәп ага, сусаганнар суын эчеп китәләр. Фазыл, ул болынга барып чыккан саен, чишмә буйларын чистартып куя, сукмагын рәтли. Ни хикмәт, монда килүчеләр торган саен күбәя. Шифасы бар, диләр, чишмәнең. Ә чишмәне «Фазыл чишмәсе» дип йөртәләр. Башлап кем әйткәндер, белгән кеше юк.

Якты күл сагышы

Якты күл үзенә бу исемне кайчан һәм кем кушканын да хәтерләми инде. Монда килеп чыккан һәркем аның яшел чирәмле ярына басып, мөлдерәп торган чиста суына карап тора да: «Һи-и, бигрәк якты инде бу күл», – ди. Тора-бара аңа «Якты күл» исеме берегеп калды. Күл бу исемне үз итте, яратты, күнекте дә.

Борынгы күл инде ул. Аның тирәсенә кешеләр күп килделәр, күп киттеләр. Түбәндә уйнаклап йөзгән акбалыкларга, яр читендәге вак камышларга, посып үскән төнбоекларга карап сокландылар, җәйге эссе көннәрдә су коенып, арыган тәннәренә сихәт алдылар. Хәтта бернәрсәдән дә шикләнмичә, аның көмештәй суын эчә дә иделәр әле. Якты күл шул ул, якты күл.

Күл яр читендә кармак каптырып утырган малайларны бигрәк якын итте. Аларның үзара сөйләшүләрен гаҗәпләнеп тыңлый, хәтта бераз көнләшә дә әле. Менә бит ничек! Аларның теле бар. Рәхәтләнеп сөйләшәләр, шаяралар, бер-берсен аңлашып вакыт үткәрәләр, гомер сөрәләр. Ә күлнең теле юк шул, ул сөйләшә дә алмый. Бары

тик талгын җил кузгаткан дулкыннары белән чапыл-чопыл килеп ярга кага, ара-тирә малайларның ялан аякларын суы белән күмеп шаярта, уйный. Монысын малайлар аңлый, көлешеп, ярдан читкәрәк сикерәләр, чыланган ыштан балакларын тезләренә кадәр сызганып, янә яр читенә килеп чүмәшәләр. Күзләрендә нур, тезләрендә кояш нурлары уйный, алларында Якты күл җәелеп киткән.

Озак гомерләр менә шулай үзара дус булып, аңлашып яшәде ул кешеләр белән.

Заманнар узды, кешеләр дә үзгәрде. Кайчандыр йокымсырап гомер кичергән авыл урамнары буйлап тау кадәр тимер арбалар чабыша башладылар. Авыл үзе дә үзгәрде, тәбәнәк, салам түбәле өйләр урынына кирпечтән зур-зур йортлар калкып чыкты. Якты күл боларны башта сокланып күзәтте, соңрак шөбһәгә төште. Күл буена килгән кешеләр торган саен рәхимсез, миһербансыз кылана башладылар. Шул тимер арбалар белән күл читенә үк туктыйлар, аларның инде күл суына исләре дә китми, ниндидер савытлардан исе әллә кайларга аңкып торган зәһәр су эчәләр, кызышалар, тавышлананалар, хәтта бер-берсенә кул да күтәрәләр. Алар киткәч, күл читендә пыяла, калай савытлар өелеп кала. Бер төркеме китсә, әллә каян дөбер-шатыр тавышлы арбаларга төялеп, икенчесе пәйда була. Кая карама чүп, чүп... Берзаман яр читендәге әрәмәләр юкка чыкты, камышлары сирәгәйде, төнбоеклар бетте. Күл өстендә уйнаклап керәшәләр очмый, акчарлаклар уйнакламый, үрдәкләр йөзми. Язлар саен оя корган аккошлар кайтмый башлады. Инде малайларны да бик аңлап бетерми Якты күл. Ягымлы түгел алар.

Аның янына хәзер күнегелгән телдә түгел, әллә нинди ят телдә сөйләшүче малайлар ешрак киләләр. Каяндыр башка җирдән кайталар, ахры, элек күлгә төшкән аккошлар кебек. Тик аккошлар кайтуына авылның бар кешесе сөенсә, бу малайларның кайтуына сөенгән кеше сирәк. Алар үзләре белән яман гадәтләр алып кайта башладылар авылга, шул гадәтләр авыл малайларына йокты. Авызларыннан төтен чыга, яшеренеп кенә бер-берсенең беләкләренә нәзек ук төртәләр, күзләреннән нур кача, аннан кыргыйларча чабып, акырышып йөриләр яр читендә. Балыклар качышып бетте хәзер, төптән күтәрелмиләр дә.

Менә бүген дә яр читенә дәү тимер арба килеп туктады. Арбага чүп-чар, таш төягәннәр. Ике кеше иде тимер арбаның өстендәге оядa. Килделәр, үзләрен хуҗаларча тотып, чүпне яр читенә бушаттылар, иркенләп гәп кордылар, авызларыннан төтен чыгарып

утырган булдылар да китеп бардылар. Якты күлнең хәлен сорамадылар, югыйсә ул тырышып-тырышып дулкыннарын ярга какты. «Нишлисез, бөтен ямем бетте, кайчандыр әти-әниләрегез, сез үзегез дә сокланган Якты күлегезне харап итәсез ич, туктагыз! Ходай хакы өчен туктагыз! Мин озак еллар сез түккән чүпне йотып бардым, төпкә озаттым, кояш күзеннән яшерергә омтылдым. Инде хәзер көч-куәтем калмады, төбем саекты. Үзем елдан-ел кечерәям, балаларыгызга ни калыр, мин бөтенләй кибеп беткәч?» – дип ачыргаланды ул, дулкыннар теле белән. Тик кешеләр аны тыңлап та тормадылар. Менә шулай кешеләр күлне, Якты күл кешеләрне аңламый торган вакыт җитте.

...Тимер арба, үкергән тавышлар чыгарып, авыл ягына чапты. Күл буена ике малай килеп басты. Су кермәкче иделәр, тынчу суга карап тордылар да кире борылып кайтып киттеләр...

Якты күл үксеп елап, аларны озатып калды. «Кешеләр сөйләшәләр, аңлаша алалар, бер-берсенә ни өчен минем хәлемне аңлатып бирмиләр икән, – дип өзгәләнде ул. – Их, мин дә кешеләр кебек сөйләшә белсәм икән!» Якты күл кайбер кешеләрнең дә инде бер-берсен аңламый башлаганнарын белми иде шул.

Болан Кояшны ничек коткарган?

Урман чишмәсеннән су эчәргә ярата болан. Аның әле яшь чагы, көчле чагы. Күкрәге киң, тармаклы мөгезе баш өстендә шундый матур утыра, күрсәң сокланып туймаслык. Карашы ягымлы үзенең, һич кенә дә усаллык юк бу караштa. Үзе дә куркуны белми. Шуңа күрә дә, таң атып килгәндә, берүзе салкын чишмәгә килеп, туйганчы су эчәргә дә курыкмый. Җитез аяклары, үткен очлы-очлы тармаклы мөгезе, зифа, җитез гәүдәсе булган болан кемнән курыксын, ди? Урман – аның үз туган йорты. Менә бу җырлый-җырлый агып ятучы чишмә дә, чәчәкле аланнар, яшь агачлар үскән ешкынлыклар – барысы да аныкы ич. Әмма сакланырга кирәклеген дә онытмый ул. Бүре явыз белән юллары кисешсә, аңа үз-үзен якларга да туры килә. Ул күбрәк ешкынлык эченә кереп китеп котыла бүре явыздан. Бүренең тешләре үткен, сизмәгәндә өстеңә ташланса, болай гына котылырмын димә!

Тагын бер нәрсәдән – кайнар уктан курка болан. Кеше дигән зат кулындагы тимер көпшәле нәмәрсәдән утлар бөркеп «шарт» итеп килеп чыга да киек җанварларны егып та сала. Кеше үзе бик хәйләкәр, искәрми калсаң, теләсә кайсы көнне кайнар укка юлыгырсың. Бермәлне боланның сыртын көйдереп үтте инде ул ук. Бик озак авыртып йөрде. Кеше ныклап тәзәп өлгерә алмый калды ешкынлыкка чабып кереп киткән боланга. Шуның аркасында гына исән калды.

Шуларны уйлап, таныш ешкынлыкка кереп барган болан бермәл агач очларына карап алган иде, кисәк тукталып калды.

Яшь агачлар үзара көлешәләр, куанышалар, серләшкән булалар. Баксаң, алар иренеп кенә урыныннан кузгалган иртәнге Кояшны эләктереп алганнар да аны җибәрми торалар. Кояш агач башында чәбәләнә, тарткалаша, яшь агачларның исләре дә китми, җибәрмиләр генә Кояшны. Агачларга кызык кына булсын. Үз уеннары уен. Кояш ни эшләргә белми, аптыраудан, ычкынып китәргә теләп көчәнүдән кызарып чыккан.

– Җибәрегез инде, минем тизрәк көнне яктыртасым бар,– дип ялына ул.

– Жибәрмибез, җибәрмибез, – дип шаулашкан була яшь агачлар. – Безнең синең белән уйныйсы килә!

Боланның ачуы килде. Ул явыз бүрене, кайнар ук атып тәнен җәрәхәтләгән, тимер көпшәсе кулыннан төшмәгән хәйләкәр кешене исенә төшерде. Кояшка ярдәм итәргә кирәк. Әнә бөтен урман ак томанга күмелгән, кошлар көтә Кояшны, үләннәр, чәчәкләр, бал кортлары. Артык түзеп булмый.

– Әй, яшь агачлар, шаярудан туктагыз! Куе ботакларыгыздан ычкындырыгыз Кояшны.

Яшь агачлар сәерсенеп боланга карап алдылар. Үзара пышылдаштылар да шаулаша башладылар.

– Һә, хәйләкәр болан, Кояшны без тотып алдык. Безнеке ул. Без әле уйнап туймадык. Уйнап туйгач карарбыз... – диделәр алар.

Болан «хәйләкәр» дигән сүзне бер дә яратмый иде. Кеше дигән зат кына хәйләкәр, ә ул – урман җанвары, үз өендә ник хәйлә корып йөрсен ди ул.

Ул көчле тоягы белән җиргә сугып алды. Тирә-якка мүкләр очты.

– Яхшылык белән җибәрегез!

– Җибәрмәсәк нишләтерсең?

Яшь агачлар аны мыскыллап көләләр иде.

Болан яшь агачларга тагын да ныграк ачуланды. Башын түбән төшерде дә тармаклы мөгезләре белән агач кәүсәләренә бәргәләп алды. Яклаучысы барын күреп, Кояш та ныграк тарткалаша башлады. Боланның үзенә ярдәм итәргә теләвенә сөенеп туймады. Йөзе яктырып китте. Тик яшь агачлар аны һаман җибәрмиләр. Болан бәлагә юлыккан Кояшны калдырып китәргә уйламый да иде.

Ул башын өскә күтәрде, Кояшны мөгезенең үткен очына сак кына эләктереп алды да яшь агачларны як-якка аерып-аерып алга китте. Мөгезгә эләккән Кояш боланга бераз ияреп барды да агачларның әрсез ботакларыннан ычкынуын аңлагач көлеп җибәрде. Болан исә Кояшны сак кына мөгез очыннан ычкындырды.

– Бар, Кояшкай, уят урманны, – диде ул, ягымлы тавыш белән. Аның тавышын кошлар сайравы, чишмә җыры күмде. Ак томанны куа-куа, Кояш биек зәңгәр күк буйлап йөзеп китте.

ЭЧТӘЛЕК

Кышның беренче көне 3

Үлән урманы 9

Сыерчык 11

Очрашу 13

Дуслык 16

Ләлә белән Арслан 19

Рәхәт көн 25

Кызык итте... 28

Фазыл чишмәсе 31

Якты күл сагышы 34

Болан Кояшны ничек коткарган? 37

Литературно-художественное издание
Для детей младшего школьного возраста

Сафин Факиль Миннемухаметович

ЛЯЛЯ И АРСЛАН

Рассказы и сказки для детей

Казань. Издательство «Магариф». 2005
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма
Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен

Сафин Факил Миңнемөхәммәтович

ЛӘЛӘ БЕЛӘН АРСЛАН

Балалар өчен хикәяләр, әкиятләр

Редакторы *Л. Ә. Гыйззәтуллина*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучысы *М. И. Данилевская*
Корректоры *Г. Г. Мөхәммәтҗанова*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Л. Р. Вафина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 20.12.05.
Форматы 60×90 $^{1}/_{8}$. Офсет кәгазе. «Ариал» гарнитурасы.
Офсет басма. Басма табагы 5,0. Нәшер-хисап табагы 4,09.
Тиражы 2000 д. Заказ З-41.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (843) 292-57-48.
Http: // magarif. kazan. ru
E-mail: magarif @ mail. ru

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

·Балалар күңеле·